РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА
БАКРЧИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
ТЕТЮШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТӘТЕШ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАКЫРЧЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

тел. (84373) 50-2-35, факс 50-2-35

**КАРАР**

**8 ноябрь 2019 ел** **№ 1**

**Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Бакырчы авыл җирлегенең Чуваш Чурапаны торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 маддәләренә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсенә, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы «Бакырчы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 маддәсенә нигезләнеп, **КАРАР БИРӘМ:**

1. 2019 елның 22 ноябрендә 9.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы Тәтеш районы Чуваш Чурапаны авылы Канаш ур. 25 йорт адесы буенча Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Бакырчы авыл җирлегенең Чуваш Чурапаны торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыены оештырырга.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районыны Бакырчы авыл җирлегенең Чуваш Чурапаны торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге бүлектә укучы студентлар, күпбалалы гаиләләр, балачактан инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның һәм аларның тол хатыннары, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларына хезмәткә чакырылган

гражданнар, иректән мәхрүм итү урыннарындагы гражданнардан тыш, 2020 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм аннан алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен, түбәндәге эшләрне башкару буенча юнәлдерүгә сез риза буласызмы:

- Чуваш Чурапаны авылы эчендәге Ленин ур., Киров ур. юлларны төзү һәм төзекләндерү;

- Чуваш Чурапаны авылы зират территориясен койма белән әйләндереп алу;

- Чуваш Чурапаны авылындагы обелиск тирәсенә брусчатка сатып алу һәм аны җәю?».

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Бакырчы авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештырырга һәм уздырырга.

4. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълъмат рәсми порталында урнаштырырга (PRAVO.TATARSTAN.RU).

5. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Тәтеш муниципаль районы**
**Бакырчы авыл җирлеге башлыгы И.М. Шамсутдинов**